ГЛАВА ВАХИТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.28, д. им. М. Вахитова,
422575

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВАХИТОВ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 28 нче йорт, М. Вахитов исем авылы,
422575

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

П К

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

31.10.2022 д. им. М. Вахитова 3

# КАРАР

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге Бакча-Сарай авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге Бакча-Сарай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юллау белән килешәсезме, - бистәдә спорт-уен мәйданчыгы төзү, дигән мәсьәлә буенча 2022 елның 31 октябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

«ӘЙЕ» «ЮК»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашкан 173 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 16 кеше кертелгән. Кворум юк.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1 Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге Бакча-Сарай авылында гражданнар җыенын узмаган дип танырга.

2 Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге Бакча-Сарай авылы гражданнар җыены нәтиҗәләрен Вахитов авыл җирлеге мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3 Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Кәримов Ф. Р.